**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 136** **«30» сентябрь 2024 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советының 24.10.2022 73 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Төги авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советының 24.10.2022 № 73 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.4. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә тикшерү үткәрелгән очраклар керми.»;

1.2. 4.7.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7.10. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-6 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми.»;

1.3. 4.9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.5. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

**Совет Рәисе** **Т.В. Попова**